**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОКТЯБРЬАВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ IV ЧАКЫРЫЛЫШ XXVIV УТЫРЫШЫ**

**КАРАР №45**

**Октябрь авылы** **16 нчы декабрь, 2022 ел**

**«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Октябрь авыл җирлегендә гавами тыңлаулар үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 24 нче февралендәге 33 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Вәрәшбаш авыл җирлеге Уставы, Мөслим муниципаль районының Октябрь авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Мөслим муниципаль районының 2022 елның 24 нче февралендәге 33 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Октябрь авыл җирлегендә гавами тыңлаулар, иҗтимагый фикер алышулар оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 6 нчы статьясындагы 1нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Гавами тыңлаулар уздыру вакытын һәм урынын күрсәтеп, гавами тыңлауларга чыгарыла торган муниципаль норматив хокукый акт проекты, гавами тыңлаулар үткәрү көненә кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча, мәгълүмати стендта бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә), шул исәптән Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында (https://muslumovo.tatarstan.ru/october.htm) урнаштырылырга, шулай ук «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән кагыйдәләр нигезендә урнаштырылырга (алга таба - Бердәм портал) тиеш.

Бердәм порталда Мөслим муниципаль районы Октябрь авыл җирлегендә яшәүчеләргә хәбәр итү максатларында гавами тыңлаулар һәм муниципаль норматив хокукый акт проектын билгеләү турында мәгълүмат урнаштыру Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының вәкаләтле хезмәткәре Октябрь авыл җирлегенең вәкаләтле хезмәткәре тарафыннан һәм Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының Октябрь кабинетын әлеге пунктның беренче абзацында билгеләнгән срокта Бердәм порталның кире элемтә платформасының тиешле бүлегендә (алга таба - органның шәхси кабинеты) башкарыла.».

1.2. 7 нче статьяны 4.1 пункты белән тулыландырырга:

«4.1. Гавами тыңлауларда катнашучылар муниципаль норматив хокукый акт проектын халык алдында тыңлауларга чыгарылган тәкъдимнәрен шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән кагыйдәләр нигезендә «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр

(функциялəр) порталы» федераль дəүлəт мəгълүмат системасы аша җибəрергə хокуклы.

Муниципаль норматив хокукый акт проекты буенча фикер алышуга чыгарылган искəрмəлəр һəм тəкъдимнəр, «Электрон формада дəүлəт һəм муниципаль хезмəтлəр күрсəтү өчен кулланыла торган мəгълүмати системаларның мəгълүмати-технологик хезмəттəшлеген тəэмин итə торган инфраструктурада идентификациялəү һəм аутентификациялəүнең бердəм системасы» федераль дəүлəт мəгълүмат системасы кулланып, Мөслим муниципаль районының Октябрь авыл җирлеге халкы тарафыннан бердəм порталдан файдаланып кертелə.

Кисəтүлəр һəм тəкъдимнəр кертү гавами тыңлауларга чыгарылган муниципаль норматив хокукый акт проектын һəм гавами тыңлауларны билгелəү турында мəгълүматны бастырып чыгару көненнəн башлана һəм гавами тыңлаулар уздыру көненə кадəр 2 эш көненнəн дə соңга калмыйча тəмамлана.

Муниципаль норматив хокукый акт проекты буенча искəрмəлəр һəм тəкъдимнəр кертелгəндə, Мөслим муниципаль районының Вəрəшбаш авыл җирлеге халкы шулай ук үзенең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), гражданның шəхесен таныклаучы төп документның реквизитлары, туу датасы һəм яшəү урыны буенча теркəлү адресы турында белешмəлəр җибəрə.

Күрсəтмəлəр һəм тəкъдимнəр органның шəхси кабинетына җибəрелə.».

1.3. 7 статьядагы 8 пунктын түбəндəге редакциядə бəян итəргə:

«8.Гавами тыңлаулар нəтиҗəлəре турындагы бəялəмə утырыш рəисе һəм секретаре тарафыннан имзалана һəм Мөслим муниципаль районының рəсми сайтында (https://muslumovo.tatarstan.ru/october.htm) һəм «Бердəм дəүлəт һəм муниципаль хезмəтлəр (функциялəр) порталы» федераль дəүлəт мəгълүмат системасында гавами тыңлаулар уздырылганнан соң 5 көннəн дə соңга калмыйча урнаштырылырга тиеш.»

2. Əлеге карарны Мөслим муниципаль районының рəсми сайтында (https://muslumovo.tatarstan.ru/october.htm), Татарстан Республикасының рəсми хокукый мəгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) Интернет мəгълүмат-телекоммуникация челтəрендə урнаштырырга.

3. Əлеге карарның үтəлешен контрольдə тотуны үз өстемдə калдырам.

**Октябрь авыл җирлеге Советы рəисе** **И.М.Ханнанов**